**Азнакай муниципаль районы**
**Әсәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әсәй авылы № 100-51 «02» октябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 14 июнендәге 33-11нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2016 елның 25.10. 42-20нче номерлы, 2017 елның 19.09. 16нчы номерлы, 2018 елның 30.01. 1нче номерлы, 2019 елның 30.12. 31нче номерлы, 2020 елның 14.04. 41нче номерлы, 2021 елның 12.10. 37-18 нче номерлы, 2023 елның 07.04. 81-39нчы номерлы карарлар редакциясендә)

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 345-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әсәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 14 июнендәге 33-11нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (2016 елның 25.10. 42-20нче номерлы, 2017 елның 19.09. 16нчы номерлы, 2018 елның 30.01. 1нче номерлы, 2019 елның 30.12. 31нче номерлы, 2020 елның 14.04. 41нче номерлы, 2021 елның 12.10. 37-18 нче номерлы, 2023 елның 07.04. 81-39нчы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 бүлекнең 1 пунктында:

а) алтынчы абзацта «, газ бүлү челтәрләре, газ куллану челтәрләре һәм мондый челтәрләр объектлары» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац белән тулыландырырга:

«- газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына карата «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 30.5 статьясында каралган башка шартлар;»;

в) сигезенче, тугызынчы абзацларны тугызынчы, унынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карар 2023 елның 23 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.З. Дәминова